**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**Сарман авыл җирлеге**
**423350 Сарман авылы, М.Жэлил ур., 63**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E - mail: Sar.sar @ tatar.ru**

**Сармановское сельское поселение**
**САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423350 с. Сарманово, ул.М.Джалиля, 63**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E – mail: Sar.sar @ tatar.ru**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ      КАРАР

**21.06.2024 г.                    № 8**

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны
түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезлә
рен билгеләү турында.

«Төбәк салымнары суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2024 елның 12 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Сарман муниципаль районының «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип та нуның өстәмә нигезләрен билгеләргә.

- варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларда 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

- Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документла түбәндәгеләр:

1) әлеге карарның 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) үлем белән бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәптән төшерү турында мәгълүмат;

в) мирас хокукы турында таныклык бирү турында мәгълүмат булмау турында салым органы белешмәсе;

2) әлеге карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда, салым органының 500 сумнан артмаган бурыч булу турында белешмәсе.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Сарман муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлеге башлыгы                                        Ф.М.Хөснуллин